РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» декабрь 2024 ел г. Альметьевск № 4238

Балачактан инвалидларга өстәмә
социаль ярдәм чаралары күрсәтү
турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына таянып, хокукый мониторинг тәртибендә, балачактан инвалидларга өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Халыкара инвалидлар көне уңаеннан Әлмәт муниципаль районында теркәлгән балачактан инвалидларга ел саен 1000 (бер мең) сум 00 тиен күләмендә бер тапкыр түләнә торган түләү билгеләргә.

Социаль ярдәм чараларын алучыларның салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаска тиеш.

Әлмәт районындагы социаль яклау идарәсе башлыгы Р.И. Гәрәевка ел саен 01 ноябрьгә кадәр балачактан инвалидлар исемлеген төзергә һәм аларны «Социаль-тернәкләндерү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә (Добровольская Л.В.) балачактан инвалидларга бер тапкыр бирелә торган түләүләр күчерү өчен тапшырырга тәкъдим итәргә.

«Әлмәт муниципаль районының социаль-тернәкләндерү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә (Добровольская Л.В.) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмнәрдә «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасын куллану юлы белән һәм «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы билгеләгән форматлар нигезендә социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

Балачактан инвалидларга социаль ярдәм буенча өстәмә чаралар күрсәтү турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмнәрдә «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасын куллану юлы белән һәм «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасы билгеләгән форматлар нигезендә алынырга мөмкин.

Балачактан инвалидларга еллык бер тапкыр бирелә торган түләүләр

җирле бюджет акчалары исәбеннән, бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә, бюджет акчаларын баш бүлүче буларак, район башкарма комитетына җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары исәбеннән тиешле финанс елында бирелә.

2. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты карарының үз көчләрен югалткан дип танырга:

- «Балачактан инвалидларга өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2016 елның 06 сентябрендәге 1997 номерлы,

- Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Балачактан инвалидларга өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2016 елның 06 сентябрендәге 1997 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 25 августындагы 1411 номерлы;

- Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Балачактан инвалидларга өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2016 елның 06 сентябрендәге 1997 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 10 декабрендәге 1811 номерлы;

- Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында»2021 елның 16 февралендәге 230 номерлы карарының 1 пунктындагы икенче абзац»

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А. М. Каюмовка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе Г.М. Хәбутдинова